ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 гыйнвар 2025 ел № 357

Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8497 номерлы Карары белән расланган муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Милли киңлек мәгълүматлары системасы» бердәм цифрлы платформасы» федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» 2022 елның 7 июнендәге 1040 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8497 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2024 елның 5 сентябрендәге 5729 номерлы Карары редакциясендә) расланган муниципаль милектәге җир участогын милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.8.2.1 пунктта:

- 8 пунктчада «территорияне комплекслы үстерү» сүзләреннән соң «яисә күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән» сүзләрен өстәргә;

- 9 пунктчада «территорияне, яки» сүзләрен «территорияне, яисә күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән» сүзләренә алмаштырырга.;

- 10 пунктчада «территорияне, һәм» сүзләрен «территорияне, яисә күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә

төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан һәм» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3.3.3.4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән киңлек мәгълүматларыннан файдалану белән бәйле аерым процедураларны башкару кысаларында милли киңлек мәгълүматлары системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3) 3.4.5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән киңлек мәгълүматларыннан файдалану белән бәйле аерым процедураларны башкару кысаларында милли киңлек мәгълүматлары системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

4) 3.5.4 пунктның икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Регламентның 3.5.2 - 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән киңлек мәгълүматларыннан файдалану белән бәйле аерым процедураларны башкару кысаларында милли киңлек мәгълүматлары системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы 14 эш көне тәшкил итә.»;

5) 3.6.2 пунктта дүртенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Техник мөмкинлек булганда процедураларны башкару, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Шул исәптән киңлек мәгълүматларыннан файдалану белән бәйле процедураларны башкару кысаларында милли киңлек мәгълүматлары системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов